ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.10.2018 г. Заинск № 1626

**“Зәй муниципаль районы Башкарма Комитетының 2016 елның 29 февраленнән 269 номерлы карары белән расланган җир кишәрлегеннән даими (сроксыз) файдалану яисә җир кишәрлегеннән гомерлек файдалану хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында”**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 нче карары, Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 29 февралендәге 269 номерлы карары белән расланган җир кишәрлегеннән даими (сроксыз) файдалану яисә җир кишәрлегеннән гомерлек файдалану хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә, аны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлек буенча урынбасары П. А. Байрашевка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И. Ф. Хафизов**

Р.Р. Шайхиев
2 80 31